РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА
УЗЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Татарстан ул., д. 8, п. Узяк, 422092
тел. (факс): (84360) 5-22-17,
E-mail: Uzk.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮЗӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

Татарстан ур., 8 нчы йорт, Үзәк бистәсе, 422092
тел. (факс): (84360) 5-22-17,
E-mail: Uzk.Tul@tatar.ru

ОКПО 04311889 ОГРН 1021607154876 ИНН/КПП 1619000431/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

**№ 3** | **«17» октябрь 2022 ел**

**«Теләче муниципаль районының Үзәк авыл җирлеге Алга торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст. , «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Үзәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Алга торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 27 октябренә 10 сәгать 30 минутка билгеләргә,Алга ФАП бинасында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы Теләче районы, Алга авылы, Мрясов ур., 6 йорт.

2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«Сез Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Алга авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 90 яше тулган гражданнардан тыш, 2023

елда 500,00 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм чараларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне чишү өчен юнәлтүгә ризамы:
- юллар буйлап үләннәр чаптыру (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Алга авылындагы янгын скважинасын бораулау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Үзәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Теләче муниципаль районының рәсми сайтында (http://tulachi.tatarstan.ru), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

В. Н. Котников